СОВЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 31.03.2023г. г. Бугульма № 6

**ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ СЕССИЯ**

**2023 нче елда Бөгелмә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,
Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Бөгелмә муниципаль районы Советы
Карар итте:

1. 2023 елда эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырылырга тиеш.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Бөгелмә муниципаль районы башлыгы** **Л. Р. Закиров**